Исполнительный комитет
Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
423655 Менделеевский район с.Тихоново ул. Шишкина д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Тихоново авыл жирлеге
башкарма комитеты
423655 Менделеевск районы Тихоново авылы Шишкин урамы 3а

тел./факс 8 (85549) 3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

2022 елның 30 маеннан № 1

**КАРАР**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
"Тихоново авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең
генераль планы проекты буенча
гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, Тихоново авыл җирлеге Уставына, гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, Менделеевск муниципаль районы Тихоновоавыл җирлеге Башкарма комитеты
КАРАР ИТӘ

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында 2022 елның 30 июнендә 16 сәгатьтә Менделеевск районы, Тихоново авылы, Шишкин ур., 3А йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Карманов А.М. - Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Филатов А.А. – Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгы урынбасары (5 номерлы округ);

Назаров В.Н. – Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге депутаты (7 номерлы округ).

3. 2022 елның 31 маеннан 30 июненә кадәр «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы материаллары экспозициясен Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Башкарма

комитеты бинасында (Менделеевск районы, Тихоново авылы, Шишкин ур., 3А) оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423655, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Тихоново авылы, Шишкин урамы, 3А йорт (Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Менделеевск муниципаль районын рәсми сайтында урнаштырырга http://mendeleevsk.tatar.ru «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

б. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.М. Карманов